# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Тирсә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14.12. 2021** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Тирсә торак пунктында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча 2021 елның 14 декабрендә 11:00, 13:00, 15:00, 18:00 сәг этаплап уздырылган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре турында түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Тирсә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертүгә һәм алардан җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен файдалануга ризамы:

1. Тирсә авылынң Озерная, Садовая урамнарында асфальтланган юлга чокыр ремонты үткәрү.
2. Тирсә авылындагы юлларга вак таш сатып алу һәм җәю.
3. Урам юлларына хезмәт күрсәтү, кар чистарту.
4. Тирсә авылын яктырту өчен тимер-бетон баганалар сатып алу һәм урнаштыру.
5. Урамнарны яктырту өчен кабельләр һәм СИП беркетмәләр сатып алу.
6. Тирсә авылында авария хәлендәге агачларны кисү.
7. Тракторга һәм янгын сүндерү машинасына ГСМ сатып алу.
8. Янгын машинасы йөртүчесенең һәм тракторчының хезмәте өчен түләү.
9. Тагылмалы чапкыч һәм бульдозер сатып алу.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 1120 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 572 кеше, бу 51 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"РИЗА" позициясе өчен гражданнар җыенында 572 катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Тирсә торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес дип танырга.

2. 2022 елда Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Тирсә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Тирсә торак пункты территориясендә, I төркем инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз өлкән гражданнардан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Армиясендә хезмәт итүче һәм иректән мәхрүм итү урыннарындагы затлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым чаралары җыюны кертергә.

3. Җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

1. Тирсә авылынң Озерная, Садовая урамнарында асфальтланган юлга чокыр ремонты үткәрү.

2. Тирсә авылындагы юлларга вак таш сатып алу һәм җәю.

3. Урам юлларына хезмәт күрсәтү, кар чистарту.

4. Тирсә авылын яктырту өчен тимер-бетон баганалар сатып алу һәм урнаштыру.

5. Урамнарны яктырту өчен кабельләр һәм СИП беркетмәләр сатып алу.

6. Тирсә авылында авария хәлендәге агачларны кисү.

7. Тракторга һәм янгын сүндерү машинасына ГСМ сатып алу.

8. Янгын машинасы йөртүчесенең һәм тракторчының хезмәте өчен түләү.

9. Тагылмалы чапкыч һәм бульдозер сатып алу.

4. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендында элеп халыкка җиткерергә, “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга (https://www.agryz.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче, И.Б. Гыйззәтуллин
Авыл җирлеге башлыгы